**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының кайбер указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының кайбер указлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы һәм 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына, «Республиканың башка башкарма хакимият органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары)» дигән IV кисәктән «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы, 2015 елның 18 мартындагы ПУ-294 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге

ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 6 апрелендәге ПУ-331 номерлы, 2016 елның 19 апрелендәге ПУ-366 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге ПУ-1075 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1192 номерлы, 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1228 номерлы, 2017 елның 15 февралендәге ПУ-143 номерлы, 2017 елның 27 апрелендәге ПУ-345 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-456 номерлы, 2017 елның 3 июлендәге ПУ-598 номерлы, 2017 елның 29 августындагы ПУ-773 номерлы, 2017 елның 9 сентябрендәге ПУ-804 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-917 номерлы һәм 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| « 13 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шул исәптән: | 154 |
| | федераль бюджет акчалары хисабына финансланучы вазыйфалар | 49 |
| | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финансланучы вазыйфалар | 105 »; |

б) 52 пунктны үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныргa:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе турында» 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-917 номерлы Указы.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 26 декабрь
№ ПУ-1168